| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.10.2021 с.Старое Дрожжаное №440

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының бушлай кайнар туклануны оештыру турында карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясына таянып, Чүпрәле районы прокурорының 2021 елның 27 сентябрендәге протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында 1-4 сыйныф укучыларына түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру турында һәм 5-11 сыйныф укучыларына туклануны оештыру хакында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 18 ноябрендәге 606 номерлы карарына (2021 елның 24 сентябрендәге 411 номерлы редакциядә) түбәндәге эчтәлекле 1.2.2 пунктына абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада яшәүче һәм тулысынча дәүләт тәэминатында булган балалардан тыш, бушлай ике тапкыр туклану белән тәэмин ителә.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов